КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 19 декабрь г.Казань № 1641

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы гомуми белем бирү оешмалары укучылары арасында «Мәктәп экопатруле» республика конкурсы турында» 2014 ел, 29 август, 619 нчы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы гомуми белем бирү оешмалары укучылары арасында «Мәктәп экопатруле» республика конкурсы турында» 2014 ел, 29 август, 619 нчы карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2015 ел, 24 август, 617 нче; 2017 ел, 29 декабрь, 1100 нче; 2019 ел, 2 ноябрь, 999 нчы карарлары нигезендә кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

5 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5. Конкурсның бүләк фонды Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы әйләнә-тирә мохитен саклау, табигать ресурсларын торгызу һәм алардан файдалану» Татарстан Республикасы дәүләт программасын раслау турында» 2013 ел, 28 декабрь, 1083 нче карары белән расланган «Татарстан Республикасы әйләнә-тирә мохитен саклау, Татарстан Республикасы табигать ресурсларын торгызу һәм алардан файдалану» Татарстан Республикасы дәүләт программасы исәбеннән төзелә дип билгеләргә.»;

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасы гомуми белем бирү оешмалары укучылары арасында «Мәктәп экопатруле» республика конкурсы турындагы нигезләмәдә:

1.2 пунктның җиденче абзацында «Татарстан Республикасы Мәгълүмат технологияләре үзәге» дәүләт унитар предприятиесенең Гражданнарның аудио һәм видеомөрәҗәгатьләрен эшкәртү үзәге» сүзләрен «Татарстан Республикасының

Цифрлы трансформация үзәге» дәүләт казна учреждениесе» сүзләренә алмаштырырга;

2.4 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәргә:

«хәбәрнамәдә күрсәтелгән адреска, координатларда сайланган объект адресына туры килми;

начар сурәтләнгән, юылган объектлар белән мәгълүмат бирелә, конкрет кешеләр образларына игътибарны юнәлтә, шәхси мәгълүматларны үз эченә ала;

зур булмаган күләмдәге калдыклар туплану турында мәгълүмат бирелә (мәсәлән, моның өчен махсуслаштырылмаган территориядә бер пар калдыклар пакеты, бер тулы чүп савыты, кәгазь кисәкләре, тышлыклар, тәмәке фильтрлары һ.б.);

йорт яны территориясендә калдыклар җыю өчен махсус контейнерлар янында, подъездларда һәм каты коммуналь калдыкларны вакытлыча җыела торган урналарда калдыклар туплану турында мәгълүмат бирелә;

янган биналарның, тузган торакның калган калдыкларын бетерү турында мәгълүмат бирелә;

ташландык биналарда калдыклар турында мәгълүмат бирелә.»;

3.1 пунктта «Конкурсны оештыручыларның уртак боерыгы белән раслана» сүзләрен «Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгы боерыгы белән раслана» сүзләренә алмаштырырга;

3.4 пунктта «конкурс» сүзен «эксперт» сүзенә алмаштырырга;

3.6 пунктта «аны алмаштыручы зат» сүзләрен «, ул булмаган очракта, рәис урынбасары» сүзләренә алмаштырырга;

3.7 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.7. Эксперт комиссиясе Татарстан Республикасы гомуми белем бирү оешмалары, сыйныфлары һәм мәктәп укучылары рейтингларын карый, гомуми утырышта катнашучыларның фото яки видеохәбәрләренә экспертиза үткәрә һәм ачык тавыш бирү юлы белән һәр номинация буенча Конкурста җиңүчеләрне билгели. Кимендә 10 балл җыйганнарга карап тикшерүдә катнашырга рөхсәт ителә.»;

4.1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.1. Конкурсны уздыру чорында Конкурс оештыручыларның рәсми соравы буенча модератор тарафыннан Конкурс оештыручылар гына кереп карый ала торган Татарстан Республикасы гомуми белем бирү оешмалары, сыйныфлары һәм мәктәп укучылары рейтингы турында мәгълүмат бирелә.»;

4.2 пунктның бишенче абзацында «җирлек рельефына» сүзләреннән соң «(туфракка)» сүзләрен өстәргә;

әлеге Нигезләмәгә кушымтаны яңа редакциядә (карарга теркәлә) бәян итәргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы гомуми белем бирү оешмалары укучылары арасында «Мәктәп экопатруле» республика конкурсы турындагы нигезләмәгә кушымта
(Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2023 ел, 19 декабрь, 1641 нче
карары редакциясендә)

Татарстан Республикасы гомуми белем бирү оешмалары укучылары арасында
«Мәктәп экопатруле» республика конкурсында җиңүчеләр өчен бүләк фонды бүленеше

| Сыйныфлар | Номинацияләр буенча җиңүчеләр | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | «Иң актив мәктәп укучысы» | | «Иң актив сыйныф» | | «Иң актив мәктәп» | |
| | урын | мәктәп укучысына бүләк | урын | сыйныфка бүләк | урын | мәктәпкә бүләк |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 |
| Шәһәр гомуми белем бирү оешмалары | | | | | | |
| 1 – 4 | 1 | 47 мең сумга | 1 | 51 мең сумга | 1 | 60 мең сумга |
| | 2 | 40 мең сумга | | | | |
| | 3 | 33 мең сумга | | | | |
| 5 – 8 | 1 | 47 мең сумга | 1 | 51 мең сумга | 1 | 60 мең сумга |
| | 2 | 40 мең сумга | | | | |
| | 3 | 33 мең сумга | | | | |
| 9 – 11 | 1 | 47 мең сумга | 1 | 51 мең сумга | 1 | 60 мең сумга |
| | 2 | 40 мең сумга | | | | |
| | 3 | 33 мең сумга | | | | |
| Авыл гомуми белем бирү оешмалары | | | | | | |
| 1 – 4 | 1 | 47 мең сумга | 1 | 51 мең сумга | 1 | 60 мең сумга |
| | 2 | 40 мең сумга | | | | |
| | 3 | 33 мең сумга | | | | |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 5 – 8 | 1 | 47 мең сумга | 1 | 51 мең сумга | 1 | 60 мең сумга |
| | 2 | 40 мең сумга | | | | |
| | 3 | 33 мең сумга | | | | |
| 9 – 11 | 1 | 47 мең сумга | 1 | 51 мең сумга | 1 | 60 мең сумга |
| | 2 | 40 мең сумга | | | | |
| | 3 | 33 мең сумга | | | | |
| «Иң яхшы муниципаль район/шәһәр округы» номинациясе – 14 мең сумга 1 урын | | | | | | |
| Бүләк урыннарының гомуми саны – 31 | | | | | | |